«Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе **РАСЛЫЙМ** **Җитәкче** **_____ Л.Ф. Нурлыева** **«30» сентябрь 2014 г.** **МП**	**«Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат»** **дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесе** **РАСЛЫЙМ** **Директор** **_____ А.К.Галиәхмәтов** **«30» сентябрь 2014 г.** **МП**

ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы – «Актаныш таңнары» Мәгълүмати-мөхәррият үзәге

РАСЛЫЙМ

Директор

_____И.Н. Хөҗҗәтов

«30» сентябрь 2014 г.

МП

Мәктәп матбугат чаралары арасында уздырыла торган

«ЯҢА ОФЫК» бәйгесенең

НИГЕЗЛӘМӘСЕ

1. Гомуми нигезләмә

1.1. «Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат» дәүләт автономияле белем бирү учреждениесе (алга таба – Гуманитар гимназия-интернат) «Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе һәм ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы – «Актаныш таңнары» Мәгълүмати-мөхәррият үзәге белән берлектә Актаныш муниципаль районының мәгариф учреждениеләре арасында матбугат чаралары (газета, журнал, радио, телевидение, электрон басма) конкурсы уздыра.

1.2. Оештыру комитеты составы, үткәрү вакыты, жюри составы гуманитар гимназия-интернат директоры тарафыннан раслана.